**ГЛАВА**
**Кудашевского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Кодаш авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.10.2019 Кодаш авылы № 1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге башлыгының 2014 елның 27 февралендәге 2 номерлы карары белән расланган “Хезмәт (вазыйфа) вазыйфаларына бәйле рәвештә бүләк алу, бүләк тапшыру һәм бәяләү, аны сату (сатып алу) һәм аны реализацияләүдән кергән акчаларны күчерү турында аерым категория затларның хәбәр итүе турында Нигезләмә”нең үз көчен югалтуын тану хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясындагы 3 өлешенең 7 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге башлыгы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге башлыгының 2014 елның 27 февралендәге 2 номерлы карары белән расланган “Хезмәт (вазыйфа) вазыйфалары белән бәйле рәвештә бүләк алу, бүләк тапшыру һәм бәяләү, аны сату (сатып алу) һәм аны реализацияләүдән кергән акчаларны күчерү турында аерым категория затларның хәбәр итүе турында Нигезләмә”не үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләренең әлеге карар белән таныштырырга.
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) http://pravo.tatarstan.ru.
4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Ф. М. ШАКИРОВ**